| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 13 декабре № 41/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә дәүләт теркәвенән соң әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырырга һәм Чүпрәле муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
3. Әлеге Карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә керә торган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көнне үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советының 2024 елның 13
декабрендәге 41/1 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

**1) 7 статьяда:**

а) статьяның **исемен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**7 статья. Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре**»;

**а) 1 пунктта:**

**9 пунктчага** «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә Район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру» сүзләрен өстәргә;

**22 пунктчада** «Район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны саклауны булдыру, үстерү һәм тәэмин итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

**28 пунктчага** «, шулай ук рекреацион максатлар өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен» сүзләрен өстәргә;

**в) 11 пунктның беренче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Район составына керүче авыл җирлекләре территориясендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә түбәндәгеләр керә:»;

**г) 4 пунктның икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Җирле үзидарә органнары, тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә, тапшырылган Россия Федерациясенең вәкаләтләрен, Татарстан Республикасының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплылык тоталар.»;

**2) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«8 статья. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы**

1. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципальара хезмәттәшлек түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә Районның әгъзалыгы;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын оештыру;

3) Район тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар оештыру;

4) шартнамәләр һәм килешүләр төзү.

3. Муниципаль берәмлекләр берләшмәләре, муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре, Район тарафыннан гамәлгә куелган коммерциягә карамаган оешмалар җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә ия була алмый.»;

**3) 12.1 статьяның 2 пунктына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктында каралган мәсьәләләрне хәл иткәндә гражданнар җыенында шулай ук гражданнар җыенын уздыру көненә 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары, әгәр бу Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән булса, катнаша ала.»;

**4) 29 статьяның 1 пунктының 26 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, район халкына рәсми мәгълүматны җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын оештыру;»;

**5) 33 статьяның 3 пунктында** «алты ай дәвамында» сүзләрен «бер ай дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

**6) 35 статьяда:**

**а) 1 пунктка** түбәндәге эчтәлекле **10.2 пунктча** өстәргә:

«10.2) аның чит ил агенты статусын алуы.».

**б) 5 пунктка** түбәндәге абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып, район Советына әлеге гариза кергән көн санала.»;

**7) 44 статьяның 3 пунктчасында:**

**җиденче абзацка** «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә Район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру» сүзләрен өстәргә;

**тугызынчы абзацны** төшереп калдырырга;

**унынчы абзацка** «, шулай ук рекреацион максатлар өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен» сүзләрен өстәргә;

**8) 48 статьяның 6 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары җитәкчеләрен билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, үз урынбасарлары арасында вазыйфаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп

тора, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана (Устав нигезендә Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын вазыйфага билгеләп кую, Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләре Район Советы белән килештереп гамәлгә ашырыла);»;

**9) 49 статьяның 3 пунктында** «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенең)» сүзләрен төшереп калдырырга;

**10) 56 статьяның 2 пунктында** «Район сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

**11) 65[1] статьяның 2 пунктына:**

түбәндәге эчтәлекле **4.1 пунктча** өстәргә:

«4.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»

түбәндәге эчтәлекле **6 пунктча** өстәргә:

«6) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен булган күрсәткечләргә системалы рәвештә ирешмәү.»;

**12) 65[2] статьяның 3 пунктына** «муниципаль хокукый акты» сүзләре алдыннан «Район Советының» сүзләрен өстәргә;

**13) 73 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«73 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе**

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Район булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында 17.12.2013 бирелгән ЭЛ ФС77-60244 номерлы таныклык яисә «Туган як» («Таван ен») район газетасында (2019-10-10 ПИ ТУ16-01689 номерлы теркәлү турында таныклык);

2) Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://droganoye.tatarstan.ru/) урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә түбәндәге адреслар буенча тоташтыру пунктлары эшли: Иске Чүпрәле авылы, Үзәк ур., 13 йорт, Район Башкарма комитеты бинасы һәм Иске Чүпрәле авылы, Үзәк ур., 9 йорт, Район Мәдәният йорты бинасы.

4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр аларны имзалаган көннән алып 7 көн эчендә, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, халыкка җиткерелә.

5. Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне, халыкка җиткерүне (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге Район Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.».

**14) 78 статьяда:**

**а) 3 нче пунктның 2 нче пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;»;

б) **4 пунктка** «белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

**15) 79 статьяда:**

**а) 1 пунктның 7 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирле бюджет акчалары исәбеннән муниципаль хокукый акт нигезендә өстәмә һөнәри белем алу;»;

**б) 3 пунктның 11 пунктчасында** «үзенең турыдан-туры начальнигын» сүзләрен «яллаучы (эш бирүче) вәкилен» сүзләренә алмаштырырга;

**16) 80 статьяда:**

**а) 1 пунктның 8 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

**б) 3 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәт узуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр тыела:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын түбәндәге очракларда биләргә:

а) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына йә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына сайлау яисә билгеләп кую, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләнгән очракта;

б) муниципаль вазыйфага сайлану яисә билгеләп кую;

в) һөнәри берлек органында түләүле сайланулы вазыйфага сайлану, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органында;

2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы тарафыннан башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиле рөхсәте белән;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру;

г) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

4) федераль законнарда башкасы каралмаган булса, ул муниципаль хезмәт

вазыйфасын биләгән йә үзенә турыдан-туры буйсынган яисә контроль астында булган муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең җирле үзидарә органында, өченче затларның эшләре буенча вәкаләтле вәкиле булырга тиеш;

5) вазыйфаи урыны белән бәйле яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм

башка бүләкләү) алырга. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр тарафыннан алынган бүләкләр, Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәр тарафыннан муниципаль милек дип таныла һәм акт буенча муниципаль хезмәткәр тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органына тапшырыла. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

6) физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән командировкаларга чыгарга, моңа җирле үзидарә органының башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, шулай ук чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит ил коммерциягә карамаган оешмалары белән үзара килешү нигезендә башкарыла торган командировкаларга керми;

7) вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булмаган максатларда матди-техник, финанс һәм башка тәэмин итү чараларыннан, башка муниципаль мөлкәттән файдалану;

8) муниципаль хезмәт белән бәйле булмаган максатларда федераль законнар нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән мәгълүматларны яисә вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган хезмәт мәгълүматын таратырга яисә кулланырга;

9) җирле үзидарә органы һәм аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата, әгәр бу аның вазыйфаи бурычларына кермәсә, гавами фикерләр, фикерләр һәм бәяләүләр, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, аларны кертү;

10) муниципаль берәмлек башлыгының язмача рөхсәтеннән башка, күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек керсә, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни берләшмәләрдән тыш) кабул итәргә;

11) сайлау алды агитациясе өчен, шулай ук референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен вазыйфаи нигезләмәнең өстенлекләреннән файдаланырга;

12) сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр мәнфәгатьләрендә үз вазифаи нигезләмәсен файдаланырга, шулай ук күрсәтелгән берләшмәләргә муниципаль хезмәткәр буларак мөнәсәбәтне гавами белдерергә;

13) җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр структурасын (һөнәри берлекләрдән, шулай ук иҗтимагый үзидарәнең ветераннар һәм башка органнарыннан тыш) төзергә яисә күрсәтелгән структураларны төзергә ярдәм итәргә;

14) хезмәт бәхәсен җайга салу максатларында вазыйфаи бурычларны үтәүне туктатырга;

15) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

16) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән финанслана торган түләүле эшчәнлек яллаучы (эш бирүче) вәкиленең язма рөхсәтеннән башка шөгыльләнергә.»;

**17) 83 статьяның 2 пунктында** «Район сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

**18) 87 статьяга** түбәндәге эчтәлекле **4 пункт** өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге электр челтәре хуҗалыгы объектларын система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына, яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы М.Р. Гафаров